ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО

МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

МӨСЛИМ

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

59 Мөслим авылы № 15.02.2017 ел.

# «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен раслау» хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен раслау хакында» (кушымта итеп бирелә)

2. Гамәлгә куючы вәкаләтләре һәм функцияләрен Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган һәм Мөслим муниципаль районы бюджеты хисабына финанслана торган муниципаль учреждение һәм предприятиеләр җитәкчеләренә Мөслим муниципаль районы бюджеты белән тәэмин итәргә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясын гамәлгә ашыру һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждениеләр, предприятиеләрнең рәсми сайтларында мәгълүмат урнаштыру (алар булганда);

- Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә җитәкче, аның урынбасарларының һәм предприятиенең баш бухгалтерының календарь елына исәпләнгән уртача айлык хезмәт хакы турында ел саен хисаптан соң килүче елның 10 мартыннан да соңга калмыйча мәгълүмат тапшыру.

1. Әлеге карар имза салынган мизгелдән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча танышырга мөмкин: http://muslumovo.tatarstan.ru

Башкарма комитет җитәкчесе А.З. Хамматов

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
РАСЛАНГАН
___________ № _____

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Мөслим муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчылары өчен уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыруның әлеге тәртибе Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларының календарь ел өчен исәпләнә торган уртача айлык эш хакы турында мәгълүматны урнаштыру тәртибен билгели, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре (алга таба – тәртип, учреждениеләр, предприятиеләр), гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

2. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәреннән файдаланучылар өчен аңлаешлы формада бәян ителергә һәм хисаптан соң килүче елның 31 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш:

-Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждениеләр, предприятиеләрнең рәсми сайтларында (алар булганда);

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждение, предприятиеләрнең рәсми сайтларында урнашырга тиешле мәгълүмат составында учреждение яки предприятиенең тулы исеме, җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 һәм 3 пунктларында каралган мәгълүмат составында Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматларны, шулай ук дәүләт серенә яки конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне күрсәтү тыела.

5. Муниципаль учреждение һәм предприятие җитәкчесе мәгълүматны хисаптан соң килүче елның 10 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән форма буенча тапшыра.

6. Башкарма комитетның оештыру бүлеге муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләре тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында хисап елыннан соң килүче елның 31 мартыннан да соңга калмыйча бастыруны тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә
1 НЧЕ КУШЫМТА

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат тапшыру формасы**

_______________________________________________________________

(муниципаль учреждениенең, муниципаль унитар предприятиенең тулы исеме)

Хисап чоры ___________ ел

| № п/п | Вазифа | ФИО (тулысынча) | Айлык уртача хезмәт хакы күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |